# *Газетабызга—60 яшь*

СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга | № 80—81 (7253—7254) | 5 июль 1991 ел. ҖОМГА | Бәясе 4 тиен.




## Үзебез турында ике сүз

(Газета укучыга мөхәррир сүзе)

Район газетасына— 60 яшь. Газетабызның юбилее —күпсанлы укучыларыбызның, журналистларның, полиграфистларның, район хезмәт ияләренең олы бәйрәме. 60 ел эчендә район газетасы зур иҗат юлы үтте. Ул елның-елында зур тәҗрибә туплап район кешеләрен халык хуҗалыгы планнарын үтәүгә мобилизацияләде, чын кеше тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш кертте.

Коллективлаштыру, индустрияләштерү, Бөек Ватан сугышы елларында, сугыштан соңгы бишьеллыкларда газета Октябрь районы хезмәт ияләренең сугышчан авангарды булды һәм бүген дә шул традицияләрне уңышлы дәвам итә. Ул уңга-сулга борылмыйча район халкының фикерен үткәреп килә.

Безнең газета битләрендә теләгән темага, теләсә кемгә бәхәсләшергә мөмкин. Җәмгыятебездән яшерен бер генә факт, күренеш калырга тиеш түгел. Бу безнең газетаның девизы. Яшерен-батырын түгел, элек теге яки бу вакыйганы ябык партия җыелышларында гына тикшереп, газетада шомартып кына бирә торган идек. Чирләрне, ялгышларны, кимчелекләрне халыктан яшердек. Кайбер нәрсәләрне күкләргә чөеп мактадык, гел ак буяулар белән генә буядык. Аерым «бөекләргә», лаек булмаса да, төрле мактаулы исемнәр бирдек. Шулай «шәхес» тәрбияләнде. Әнә шулардан әхлаксызлык тамыр җәйде, партиянең абруе төште, җинаятьчелек күбәйде.

Соңгы елларда үзгәртеп кору җилләре кешеләрнең бераз күзләрен ачты, әйтер сүзләрен әйтергә мөмкинлек туды. Ләкин бу әле башлангыч кына. Без, газета хезмәткәрләренә эшләү өчен барлык киртәләр дә алып ташланды дип әйтә алмыйбыз. Әлеккеге яшәп килгән тоткарлыклар бер җирдән алынса, икенче җиргә ныклабрак урнаштырылып куела. Кызганычка каршы, кайбер җитәкчеләр үзләренең эшчәнлекләрендә газетаны файдалану урынына аның битләрендә күренгән тәнкыйть материаллары өчен журналистларны ачыктан-ачык эзәрлекләүләргә, куркытуларга, төрле янауларга кадәр барып җитәләр. Редакция хезмәткәрләренә карата ялган уйдырмалар тарату, алар адресына башкаларны котыртып шикаятьләр яздыру алымнарын кулланудан да чирканмыйлар.

Шулай да бүгенге газета тәнкыйте тамырдан үзгәрә. Әгәр элек без газета битләрендә хезмәт коллективындагы җитешсезлекләр өчен җитәкченең фамилиясен генә күрсәтеп калган булсак, бүген шул кимчелекләрне китереп чыгарган сәбәпләрне эзләп табып, аларны бетерү өстендә эшлибез!Бу мәсьәләдә безгә, район журналистларына район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов зур ярдәм күрсәтә. Газета битләрендә урнаштырылган бер генә тәнкыйть материалы да аның игътибарыннан читтә калмый.

Соңгы елларда газета битләрендә экономик мәсьәләләр, алдынгы тәҗрибәне пропагандалау, дуслык, патриотизм темаларына зур урын бирелә. Хәер, газетабыз укучыларның күз алдында. Аның тиражы елдан-ел арта бара. Бүген ул 13 меңнән артык тәшкил итә. Газетаны районыбызда 40 меңнән артык кеше укый. Әлбәттә, ирешелгәннәр тынычландырмый. Алда эшлисе эшләребез, чишәсе проблемаларыбыз күп. Редакциядә тәҗрибәле, гадел, куркусыз, тәвәккәл кадрлар эшли. Алар белән алда торган проблемаларны һичшиксез хәл итә алырбыз дип уйлыйм. Бүгенге бәйрәм көнендә мин газета хезмәткәрләрен Р. Г. Нуретдинова, З. И. Яллина, Е. Т. Илюшкина, Р. З. Айзатуллин, С. Н. Хәйруллина, Г. М. Халиуллина, К.Б.Җамалетдинова,Н. Н. Северина, З. М. Вәлиева һ.б. иптәшләрне бәйрәм белән тәбрик итәсем килә.

Газетабызның юбилее уңае белән матбугат ветераннарына, журналистларга, газетаның актив хәбәрчеләренә һәм укучыларына кайнар сәлам юллыйм, аларга зур иҗат хезмәте, сәламәтлек һәм бәхет телим.

**Ә. У. АБДУЛЛИН,**
**район газетасы мөхәррире.**

Район халык мәгарифе бүлеге «Дуслык»ны олы юбилее белән кайнар котлый, аңа иҗат уңышлары тели. Киләчәктә дә яшь буынны тәрбияләүдә кулга-кул тотынып, килешеп эшләргә насыйп итсен.

**«ДУСЛЫК» РАЙОН ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕНӘ, ТИПОГРАФИЯ КОЛЛЕКТИВЫНА, АВТОРЛАР АКТИВЫНА**

КАДЕРЛЕ ИПТӘШЛӘР! Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы, КПСС райкомы, журналистларны, полиграфистларны, авторлар активын һәм укучыларны «Октябрьский колхозник», соңыннан «Дуслык» («Дружба», «Туслах») итеп исемләнгән район газетасының беренче саны чыгуның 60 еллыгы белән кайнар котлыйлар. Сез хәзер кулыгызга алган газетаның соңгы санын беренчесеннән 7253 сан аера. Эшчеләр типографиядән буяу исе аңкып торган беренче санны кулларына алган иртәдән соң 60 ел узган.

Беренче бишьеллыклар елларында оешкан газета район партия оешмасының сугышчан ярдәмчесе булды, район хезмәт ияләрен тәрбияләүгә зур өлеш кертте.

Газета битләре—район хезмәт ияләренең беренче бишьеллыклар, Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары елъязмасы. Газета промышленность предприятиеләре, колхоз һәм совхозларның районның социаль һәм экономик үсеш планнарын үтәүдәге өлеше турында сөйли.

Бүген халык яңа катлаулы бурычларны күп вакыт билгесез юл сайлап хәл итә.

Шушы катлаулы чорда да газета хезмәтнең,хуҗалык,идарә итүнең алдынгы алымнарын конкрет мисалларда, эшне тирән аңлап, һәркем күңеленә җитәрлек итеп, оператив пропагандалый. Матбугат укучыларның барлык көчен, энергиясен һәм иҗат потенциалын беренче чираттагы бурычларны—кризисны тиз бетерү, гражданнарның үзара тыныч һәм дус яшәүләренә ирешү, барлык үзгәртеп кору, демократик көчләрнең бердәмлеген тәэмин итү бурычларына туплый.

Безнең газета «Дуслык» исемен тикмәгә генә йөртми. Аның исеме җисеменә тәңгәл килә. Район халкының күпмилләтле составы, аның нык, эшлекле элемтәсе бу исемне аклый.

Газетаның үзенең үзгәрмәс кагыйдәсе бар. Ул шәһәр һәм авыл кешеләренең бердәм, тату гаиләгә тупланып халыкның тормыш дәрәҗәсен, культурасын үстерү һәм экономикасын күтәрү бурычларын хәл итүләрен чагылдыра.

Газетага боларның барысына да ирешүдә халык белән өч телдә—татарча, русча, чувашча сөйләшү ярдәм итә. Без ышанабыз, газета үзенең югары билгеләмәсен намус белән йөртер, үткен сүзе белән җәмгыятебез алдында торган социаль, экономик бурычларны хәл итүгә булышыр.

Газета журналистлары Совет журналистикасы принципларына нигезләнеп югары җәмәгать активлыгы күрсәтерләр һәм җаваплылыкларын арттырырлар дип ышанабыз.

Редакция коллективына, аның эшче һәм авыл корреспондентларына яңа иҗади уңышлар телибез.

**ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.**
**КПССНЫҢ ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ.**

### 60 ел яшәгән „Дуслык" ул

Дуслык—ул олы хис, изге хис,
Урыны йөрәкнең түрендә.
Бу сүздә чагыла ышаныч,
Ихтирам, якынлык күңелгә.
Татарның, урысның, чувашның
Берлеген ныгыткан изге сүз.
«Дуслык» ул—районның көзгесе,
Һәр йортта кадерле, якын, үз.
60 ел яшәгән «Дуслык» ул,
Үткәнгә тарихи елъязма.
Гасырлар үтсәң дә тугры кал,
Шул хисне нык сакла, юл язма!

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

**ЮБИЛЕЕҢ БЕЛӘН, «ДУСЛЫК»!**

Татарстан республикасы «Шәфкатьлелек» девизы белән чыкты. Мин «Дуслык» газетасы редакциясенә йомышым төшеп мөрәҗәгать итәм. Ул миңа чын дус, киңәшче буларак, кешеләр белән элемтәдә торырга булыша.

Мин газетаның барлык хезмәткәрләрен олы юбилей белән котлыйм.

**В. БАТРАКОВА.**

